ISSN 0868-4545



Салават күпере





Рәссам
Илдар НӘФИЕВ

© "Салават күпере", 2006 ел

Без – Тукай шәкертләре

Тышта – кыш.

Урамда – буран, җил сызгыра...

Өйдә – җылы, рәхәт.

Буран тынса, көн җылынса, урамга уйнарга чыгарбыз ла анысы... Тик... Көн рәтләнми бит әле бер дә – дулый да уйный буран, сызгыра да ыжгыра җил...

Хәер, дуласын ла буран, сызгырсын ла җил – туктарлар әле бер, арыгач, хәлләре беткәч... Яңа елга да күп калмады инде... Буран да, җил дә быел дулап-сызгырып калсын әйдә...

Өлкәннәр әйтмешли, аларның – бездә, безнең аларда эшебез юк – менәтрәк!

Иң мөһиме – без өйдә.

Син шигырь язасың, мин – әкият... Юк, мин рәсем ясыйм, син хикәят язасың... Әллә киресенчәме?!

Иң мөһиме – без иҗат итәбез...

Без – Тукай шәкертләре:

Энҗе сүзләр, мәрҗән уйлар
Ак кәгазьгә тезелә –
Минем күңел агачыннан
Шигъри тәлгәш өзелә...

Тукай абый

Тукай абый! Синең иҗат –
Һәркем өчен якты үрнәк.
Синең «Кәҗә илә Сарык» –
Нәниләргә бик зур бүләк!

Тукай абый! Кечкенәдән
Үстек «Туган тел»не тыңлап.
«Шүрәле»не укыдык без
Кырлай, синең хакта уйлап.

Тукай абый! Уйнаса да,
Моңлы сазың бик-бик тә аз.
Һәммәбезне һәр ел саен
Синең янга китерә яз.

Тукай абый! Гасырлардан
Гасырларга күчәрсең син.
Еллар үтәр, сулар агар...
Мәңге-мәңге яшәрсең син!

Айсинә һәм Айгөл ӘХМӘДИЕВАЛАР.
Әгерҗе, Исәнбай.

Түбән Камадагы 8 нче урта мәктәпнең IV сыйныф укучысы Диләрә Шакирҗанова беренче сыйныфтан башлап, барлык фәннәрдән дә «4» һәм «5» билгеләренә генә укый. Татар теле, рус теле, уку, рәсем, математика дәресләрен аеруча нык ярата. Бик күп әдәби китаплар укый.

Диләрә «Гарәп графикасы» һәм «Шахмат» түгәрәгенә йөрергә дә вакыт таба.

«Ул – тырыш, тәрбияле, тыйнак, шәфкатьле», – диләр сыйныфташлары аның турында.

Диләрә һәрвакыт чиста, пөхтә киенеп йөри.

Мәктәп һәм шәһәр күләмендә үткәрелгән төрле кызыклы бәйгеләрдә бик теләп катнаша һәм еш кына призлы урыннарны алып килә.

Шундый күркәм бәйгеләрнең берсендә («Без – кояш балалары») катнашып, ул күренекле якташы, җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь Разил Вәлиев исемендәге дипломга лаек булды. Афәрин, Диләрә! Яңадан-яңа уңышлар телибез сиңа!

Хәзер Диләрәнең иҗатыннан шигырь тәкъдим итәбез.

Безнең гаилә

Гаиләдә без өч кеше:
Мин, әти һәм әнием.
Күңеллерәк булыр иде –
Булса тагын бер энем.

Әтием һәм әниемне
Бик тә, бик тә яратам.
Аларны сөендерергә
Мин көн дә «5»ле алам.

Дәресләремне әзерләп,
Кайвакыт бик тә арам:
Китап укыган җиремнән
Йокыга китеп барам...



Диләрә Шагыйрь абый –
Разил Вәлиев янәшәсендә.



Кыш

Кар бөртекләре
Җиргә ятканнар.
Диңгезгә, суга
Бозлар япканнар.


Кыш бабай килгән
Яңа елга дип.
Кар алып килгән
Балаларга дип.

Гөлназ БӘДРЕТДИНОВА, 10 яшь.
Арча, Шурабаш.



Рәссам Светлана ПРИВИНА





Мөдәррис Әгъләмов шигырьләре

Өй саклаганда

Тәрәзәдән карап торам,
Нигә але карамаска!
Каравы да ярап тора,
Нигә але ярамаска!

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар.
Мине Суык бабай тышка
Чыгармый дип уйласыннар.

Янәшәмдә нәни энем,
И сөенә, торып баскан.
Тәпи атламакчы була,
Нигә але атламаска!

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар!
Мине әти-әни өйдән
Чыгармый дип уйласыннар.

Әти эштә, әни эштә.
Энем тәпи өйрәнүгә,
Тау шуарга, кар көрәргә
Чыгачакбыз бергә-бергә.

Ә малайлар уйнап йөри,
Уйный икән уйнасыннар!
Җылы өйдә үзе генә
Утыра дип уйласыннар.

Болыт

Бер йомгак кебек булып,
Тәгәрәп чыкты болыт.
Башта бик нәни иде,
Җил аны назлап сөйде.
Үчти-үчти иттерде,
Сөя-сөя үстерде.
Менә аякка басты,
Офыкларга тоташты.
Ай үсәсен көн үсте,
Түгә-түгә күз яшен.
...Болыт кына булсаң да,
Үсү авыр, күрәсең.

Әкият башы

Борын-борын заманда,
Безнең әби-бабайлар
Атынганда таганда;
Җир кирегә әйләнгәндә,
Җәен карлар яуганда,
Кошлар кышын бездә калып,
Язын китеп барганда;
Без коенган елгадагы
Сулар үргә акканда;
Кояш көнбатыштан чыгып,
Көнчыгышка батканда,
Яшәгән, ди, яшәгән...
Яшәгән, ди, шул менә...
Кем яшәгән? Нишләгән?
Мин башладым,
Син сөйлә!

Рәссам
Фәрит МУЛЛАХМӘТ







– Апаны җигеп чанага,
Кышкы, караңгы төндә,
Чыгып киттем мин сәфәргә...
Кызыкмыйсызмы сез дә?

Азнакай.



Луиза, 6 яшь
Альбина, 4 яшь



Гүзәл, 2 яшь 1 ай
Инсаф, 1 яшь 10 ай

– Алай түгел, менә болай
Басарга кирәк башта.
Үпкәләмә, һич җыенмыйм
Биергә синнән башка.

Теләче, Олы Мишә.

– Хыялланам: «Мең сум акчам,
Их, хәзер булса иде!..
Рәсемдәге җиләк-җимеш
Өстәлдә торса иде!»

Саба, Шәмәрдән.



Айсинә, 9 ай



Зәринә, 2 яшь 4 ай, Гадел, 2 яшь 11 ай

– Туп-туры бас, алга кара –
Беркая да бармыйсың!
Миңа килеп каптың инде –
Хәзер котылалмыйсың!

Кама Тамагы, Олы Салтык.

Кыш бабай бүләге

Матур бәйрәм җырыбыз
Яңгырагач еракка:
Кыш бабабыз ишетеп,
Килде безгә кунакка.

Елмаеп ул эндәшә:
«Исәнмесез, дусларым!
Ямьле бәйрәм кичендә
Яусын сезгә котлавым.

Нинди әйбәт уйныйсыз
Яшел чыршы янында.
Бүләк биреп, мин сезне
Шатландырыйм тагын да...»

Әнәс КАРИ.

Кадерле дустым!

____

____

____

____

____

____


ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН



Малайларга көч бирә, кызларга матурлык өсти

Казан шәһәрендәге 2 нче икмәк пешерү заводы җитештергән бу тәмле ипи-күмәчләр түбәндәге кибетләрдә сатыла:

Декабристлар ур., 164 нче йорт, 1 нче кибет
Восстание ур., 52, 31 нче йортлар, 3 һәм 11 нче кибетләр
Ленская ур., 4 нче йорт, 5 нче кибет
Икмәк заводы ур., 7 нче йорт, 14 нче кибет

Ипекәй турында чын әкият

Борын-борын заманда әле син дә, әле мин дә булмаганда безнең бабайлар ипи ашамаган ди. Чөнки ул вакытта ипекәй бөтенләй булмаган, аның ни икәнлеген белмәгәннәр.

Кешеләр борчак ашаган һәм кәбестә ашаган. Менә берзаман, иписез генә ашаганга күрә, боларның эчләре авырта башлаган ди. Нишләргә икән соң, дип баш ваткан безнең бабайлар. Һәм шуннан соң, ике бик акыллы кешене сайлап алып, дөнья буйлап сәяхәткә чыгарып җибәргәннәр. Җирдә үскән һәр үләнне, һәрбер үсемлекне тикшереп карарга кушканнар.

Бик озак эзләгән болар. Менә, ниһаять, моңарчы үзләренә таныш булмаган үсемлек очраталар. Үсемлек телгә килә:

– Мин арыш уҗымы булам. Кешеләр теләсәләр, минем орлыклардан икмәк дигән ашамлык ясый алалар. Икмәк эч авыртуын баса. Икмәк балаларга тизрәк зур үсәргә ярдәм итә, – ди.

Теге ике кеше моны ишеткәч, бик сөенә инде. Икмәк турында тагын сораштыра болар. Арыш уҗымы бик теләп җавап бирә:

– Мин көзгә сап-сары арыш булып өлгерәм. Алтын башакларым да булачак. Менә шул башакларымдагы орлыктан он ясыйсы була. Ә оннан исә ипи пешерергә мөмкин.

Икмәк пешерү өчен мич кирәк була бит инде. Китә болар Казанга кайтып һәм Левченко дигән бистәдә зур бина салып куялар, анда бик зур ипи мичләре ясыйлар. Тора-бара әлеге бина икмәк заводына ук әйләнеп китә. 2 нче номерлы икмәк заводы. Ә аның кибетләрендә сатыла торган ипекәйләр... Нәкъ менә шул ипекәйләрне ашаган малайлар бик тиз генә буйга үсеп китеп... чын баһадир була икән. Ә кызлар... кызлар дөньядагы иң чибәркәйләргә әйләнәләр икән.

Шуннан бирле берәүнең дә эче авыртмый башлаган икән.

Менә сиңа мә, чын әкият бит бу!

Кадерле дускай!

Икмәк, ипи, ипекәй ничек ясала? Шул хакта инша язып, редакциягә җибәр.


Салават, 5 яшь

– Җылы киемнәр киеп,
Чыктык ишегалдына.
Хәзер ауга китәбез,
Хәл алыйк та аз гына.

Әтнә, Яңа Шашы.




Регина, 3 яшь
Ришат, 5 яшь


– Эшем күп – эш муеннан!
Вакыт калмый уенга:
Ары чабам, бире чабам –
Машинасыз кыен ла...

Әтнә.


Айдан, 2 яшь 3 ай
(җырчы Булат Нигъмәтуллинның улы)

– Музыкант булыйм
микән, –
Гитара уйныйм микән?
Әллә әтием кебек
Шәп җырчы булыйм
микән?!

Казан.


Зөһрә, 6 ай
Айсылу, 7 ай

– Аякларны селкетеп,
Күнегүләр ясыймын:
Иртәгә мин, ниһаять,
Тәпи йөри башлыймын!

Мамадыш.

Марат белән Римма – Азнакайдан. Ике бертуган шәһәрдәге татар гимназиясендә белем ала. Марат – алтынчы, Римма сигезенче сыйныфта укый. Икесе дә әдәби китаплар, аеруча шигырьләр һәм әкиятләр укырга яраталар. Үзләре дә каләм тибрәтә башлаганнар әле, рәхмәт төшкерләре! Әйдәгез, сүзне озынга сузмыйча, Марат белән Римманың үз иҗат җимешләрен авыз итик...

Бүреләр белән этләр

Әкият

Борын-борын заманда, куе караңгы урманнарда бүреләр белән этләр бергә дус яшәгәннәр. Еллар уза торган. Бер елны яз көннәрендә азык табу кыенлашкан. Бүреләр һәм этләр ризык эзләп, ерак аралар узганнар. Беркөнне юлларында аларга куян очраган. Бүреләр куянны тиз генә ашарга уйласалар да, этләр ашыкмаска кушканнар.

– Куян, син кая барасың? – дип сораганнар. Ул авылга кәбестә белән кишер сатып алырга баруын әйткән. Бүреләр белән этләрнең акчалары булмаса да, алар куяннарга ияреп авылга сарык-сыер итен алырга киткәннәр. Куян үз акчасын түләп, кәбестә белән кишер алып, кире урманга йөгергән.

Бүреләр, хезмәт итмичә, бушка гына ит алып, авылдан качмакчы булганнар. Этләр исә, хуҗаларыннан сорап, аларга хезмәт итеп кенә азык-төлек алу ягында булганнар.

Бүреләр белән этләр арасында көчле каршылык килеп чыккан. Шул көннән башлап, этләр кешеләргә хезмәт иткәннәр, ә бүреләр урман-кырларда качып яши башлаганнар.

Марат ШӘЕХОВ.

Рәссам
Диләрә НӘҮРҮЗОВА







Болытлар

Сокланырлык матур булып,
Күктә болытлар йөзә.
Әкрен генә йөзсәләр дә,
Алар күп җирләр гизә.
– Әй, болытлар, кошлар сыман,
Кайларга юл тотасыз?
Көннәрегез давыллымы,
Төннәрегез – йокысыз?
Назлап-сыйпап үтәсезме
Урманнарны, киң кырны?
«Олаулар»да кар-буранмы,
Әллә җылы яңгырмы?
Мизгел саен үзгәрәсез,
Күк йөзләрен яңартып,
Сафлык биреп күңелләргә,
Бар уйларны агартып...

Әбием киңәше

Бер минут та әбием
Тик утырмый — гел эштә!
Чүпләп бетермәс эшләрен
Хәтта тавык-чебеш тә.
Йөгерә дә йөгерә ул,
Ничек шулай өлгерә?
Атлап кына йөрми шул ул,
Яшьләр кебек җилдерә!
Баштан сыйпый-сыйпый, әби
Биреп куя киңәш тә:
«Яшьтән тырыш булсаң, балам,
Өлгерерсең һәр эшкә!»

Римма ШӘЕХОВА.





Илнар ХӘБИБРАХМАНОВ, 5 яшь. Балтач, Яңа Салавыч.



Шакмадрат

Мәзәк

Бервакыт дәрестә укытучы квадрат турында аңлатты да, бездән сорады:

– Балалар, нәрсә булды инде бу?

– Шакмак! – диде беребез.

Икенче бер укучы болай дип җавап бирде:

– Шакмадрат.

Без шаркылдап көлеп җибәрдек.

Альмира ДӘҮЛӘТОВА, 11 яшь.
Саба, Сатыш.

Кәҗә белән булган хәл

Хикәя

Иртән әтине эшкә озатып урамга чыктым. Урамда бүтән бер кеше дә юк. Тыкрык башында бер кәҗә кычкырып тора. Мин капканы япканчы, кәҗә безнең капка төбенә килеп тә басты. Шулвакыт безнең этебез каты итеп өрә башлады һәм ычкынып та китте. Ул кәҗәне куа, мин алар артыннан чабам. Кәҗә миннән алда өйгә кереп тә китте. Мин тиз генә ишекне яптым. Кәҗә өй эчендә калды. Нишләргә дә белмим. Кәҗәне куа башладым, ә ул өйдә тик чабулап йөри. Шуннан соң этне ябып куйдым һәм кәҗәне өйдән куып чыгардым. Аны килгән ягына озатам, ә ул миннән алда тагын капка төбенә килеп җитә. Шулай итеп, берничә тапкыр куыштык та, мин арып өйгә кереп киттем. Кәҗә мин кабат чыкканда урамда юк иде инде.

Рушат СОЛТАНШИН, 9 яшь.
Кукмара, I нче татар гимназиясе.



Наилә СӘМИГУЛЛИНА, 6 яшь.
Яр Чаллы.



Ранис ГАЛИЕВ, 8 яшь.
Арча, Яңа Кенәр.

Чәчәкләр нигә елый?

Әкият

Яшәгән, ди, бер чәчәк.

Урман караңгы булганга, чәчәккә кояш нурлары үтеп керә алмаган. Бер көнне көчле җил чыккан. Урманда бик күп яфраклар коелган. Чәчәккә дә якты булып киткән. Ул бик сөенгән. Тагын да матурланган. Шулчак урманга бер малай килеп кергән һәм чәчәкне өзеп алган. Кояшны күреп сөенгән чәчәк елап җибәргән. Ләкин малай аны аңламаган.

Чәчәкләрне елатмас өчен, өзмәскә кирәк. Дөньяны ямьгә төреп, күзләребезне сөендереп үссеннәр алар.

Шамил ДАУТОВ,
Яр Чаллы шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге
2 нче татар гимназиясе укучысы.



Эльвина ӘХМӘТШИНА, 7 яшь.
Яшел Үзән, Күгеш.



Гүзәл ИСЛАМОВА, 11 яшь.



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Туган авылым

Туган авылым Борнак минем –
Матур авыл:
Тау астында, иңкүлектә
Утыра ул.

Зур да түгел, кечкенә дә –
Ул уртача.
Һәрбер йортның тирәсендә –
Матур бакча!

Авылымны урап алган
Агачлыклар;
Таңнан кичкә кадәр сайрый
Анда кошлар.

Челтер-челтер чишмә ага
Тау башыннан...
Авылымны танып була
Әнә шуннан.

Гөлинә НӘҖИПОВА, 12 яшь.
Балтач, Борнак.



Нүрисә ХӘЙРУЛЛИНА,
8 яшь.
Кукмара, Югары Казаклар.





Илүзә ХАРИСОВА,
8 яшь.
Азнакай, Сәпәй.



Гүзәл ТАҖИЕВА, 9 яшь.
Мамадыш, Көмеш Күл.

Салават күпере

11-12 (200-201) — 2006

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЖИР, МИЛЕК МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕКТИВЫ.
1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛИ: МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РТ, ПРАВЛЕНИЕ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И КОЛЛЕКТИВ РЕДАКЦИИ.
Основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Диләрә НӘҮРҮЗОВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта А.АЙСИНА рәсеме
Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 16.11.2006 ел.
Басарга кул куелды 16.11.2006 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 10062 данә. Заказ 3-1010.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, Н.Акмал, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Кар малай

И тырыштык, и эшләдек –
Бездә җегәр бар, малай:
Шундый-шундый зур итеп, без
Ясап куйдык Кар малай!

Бәхтияр ГЫЙЛЬФАНОВ,
12 яшь. Казан.

